КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 31 октябрь г.Казань № 977

Балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләренең тулы күләмдә финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләренең тулы күләмдә финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.

2. Әлеге карар 2020 елга (2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына) Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла дип билгеләргә.

3. 2020 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 21 декабрь, 1204 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

4. 2. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин